МАЛ ҺӘМ ТОРМЫШ КАДЕРЕ

Мөслим районындагы авылда гадәти булмаган токымлы сарыклар үрчетәләр

> 2



БЕЗ ЯШӘГӘН ДӨНЬЯДА

«ВТ» хәбәрчесенең ил-көндәге һәм дөньядагы вазгыятькә күзәтүе

> 2

ХӘСРӘТЛЕ БАЛАЧАК

Сугыш гүзәл хатын-кызлардан да батырлык таләп иткән

> 3

БӘЙРӘМ КАЙТАВАЗЫ

Казанда, Чаллыда, Ульяндa Сабан туйлары гөрләде

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 86 (28859) | Сишәмбе | 21 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

СЕЗ ИҢ КИРӘК КЕШЕ ИКӘНСЕЗ

Шәфкать

«Һаман ышанып бетә алмыйм!» «Ак чәчәкләр» бәйгесендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның махсус бүләге – «Лада» машинасына лаек булган фельдшер Рәзинә Мөгыйнова әле бүген дә бәйрәм тантанасында алган тәэсирләр белән яши. Баулы районы Мортаза фельдшер-акушерлык пунктын җитәкләүче Рәзинә ханым бу җиңүен 32 еллык фидакарь хезмәтенә зур бәя дип саный.

tatarstan.ru

«Фәрит Мөхәммәтшин сәхнәдән исемемне игълан иткәч, шок хәлендә калдым. Каушаудан кулдан телефоным төшеп китте, аякларым тотмаска әйләнде. Кулга машина ачкычын алгач, ничек кире үз урыныма төшеп утырганны да хәтерләмим. Минем хезмәтемне шулай югары бәяләрләр дип кем уйлаган! Мин шушы бәйрәм тантасында шундый атаклы, легендар табиб, белгечләр белән бер залда утыруым белән үк бәхетле идем», – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә. Хәер, ул көнне Рәзинә апаның нинди хисләр кичергәнен бөтен зал тойды бугай. «Икейөзләнә белмим шул, ничек бар – шулай. Шатлыгым да, борчуым да йөземә чыга», – дип тыйнак кына елмая ул үзе. Күңеле сизгән, күрәсең, узган ел Рәзинә апаның бик нык машина йөртергә өйрәнәсе килә башлый. Шул рәвешле тормыш иптәше белән «тимер ат»ны иярләү серләренә төшенгән ул. Хәзер менә машина йөртү таныклыгы алырга җыена. Тәҗрибәле фельдшер авырулары янына җил тизлегендә генә барып җитәчәк. Әлеге җаваплы һөнәрне сайлаган кешенең һәр секунды исәптә бит.

Рәзинә Мөгыйнова бүген 262 кеше яшәгән Мортаза авылы халкына хезмәт күрсәтә. Җәйгә кунакка кайтучылар белән бергә аларның саны 500гә җитә икән. Узган ел 400ләп кеше гомер иткән күрше Кырым-Сарай авылы да Рәзинә апа карамагына күчкән. Шушы авылдан чыгып, хәзер чит төбәкләрдә, Әлмәт, Мәскәү шәһәрләрендә яшәүче авылдашлары да, киңәш-табыш, ярдәм сорап, әле дә Рәзинә апага шалтырата икән. Бу – үзе үк аның хезмәтенә зур бәя бит!

Дөрес, хезмәт юлын башлаганда төрле чак булган. «Мин кечкенә чакта гел курчаклар, хайваннарны дәвалап уйный идем. Унынчы сыйныфны бетергәч, иптәш кызым белән медицина көллиятенә укырга кердек. 1990 елда аны тәмамлап, авылга фельдшер булып эшкә кайттым. Эшли башлаганда 20 яшьлек кыз идем», – дип искә ала ул елларны Рәзинә Мөгыйнова. Яшь-яшь кызга авыл халкының ышанычын яулау җиңел булмый, билгеле. Баштарак халык яшь фельдшер янына килергә ашкынып тормый. Әмма эшли-эшли тәҗрибә туплана. Хәзер инде авылдагы медпункт ишегенең ябылып торганы да юк.

«Кеше гомереннән дә кадерле нәрсә юк. Безнең эштә иң беренче чиратта әнә шул кагыйдәне истә тотарга кирәк. Кешеләргә карата игътибарлы, ихтирамлы, киң күңелле булсаң гына эшли аласың. Фельдшерга батыр йөрәк тә кирәк», – ди Рәзинә Мөгыйнова. Батырлык дигәннән, күптән түгел үзенә дә ике яше дә тулмаган баланың гомерен саклап калырга туры килә. Имин булмаган гаиләдә тәрбияләнүче сабыйны бер кат киемнән генә өшегән, аңсыз килеш сап-салкын йортта табып ала ул.

Башкача мөмкин түгел

Шушы дәрәҗәле бәйгедә җиңүченең исемен атаган Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да табибларга соклануын яшермәде.

– Иң авыры – кешеләр белән эшләү. Сез бит әле сырхаулар белән дә эшлисез. Алар белән эшләгәндә никадәр сабырлык, мәхәббәт, үзгә мөнәсәбәт кирәк. Менә шушы сыйфатлар безнең Татарстан табибларына гына түгел, Россиянең барлык сәламәтлек саклау тармагына хас. Килеп туган вазгыять табиб һөнәренең заман таләбенә туры килүен раслады, – диде парламент башлыгы.

«Ак чәчәкләр» бәйгесе елдагыча биш номинациядә узды. Бәйгенең төп җиңүчесе, «Ел табибы» дип Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш йөрәк-кан тамыры хирургы Роин Джорджикия табылды. 50 елдан артык гомерен шушы һөнәргә багышлаган табиб студент елларында ук хирургия белән кызыксынган, күп кенә операцияләрдә катнашкан, фәнни-тикшеренү эше белән шөгыльләнгән.

Роин Джорджикия, Татарстанда беренчеләрдән булып, йөрәк клапаннарын протезлау, ритм бозылганда ясала торган операцияләрнең нечкәлекләрен өйрәнгән. 2010 елдан башлап республикада беренче тапкыр аның җитәкчелегендә йөрәк күчереп утырту операцияләре ясала башлаган. Бүген аның донор йөрәкле пациентлары сау-сәламәт.

Бер кеше гомерендә бәяләп бетергесез зур хезмәт булса да, Роин Джорджикия үзе гадәти эш башкарам дип саный.

– Безнең республикада миңа караганда да зуррак казанышлары булган табиблар бар. Бу номинациядә җиңәргә дип омтылмадым. Эшләдем дә шуның белән шул, – диде ул сәхнәдән тыйнак кына. – 70 нче елларда Грузиядән Татарстанга килдем. Университетка укырга кереп, Татарстанның данлыклы медицина тармагында кайный башладым. Татарстанда шәхес үсешенә, бигрәк тә сәламәтлек саклау тармагына зур игътибар бирелә. Ирешкән казанышларыбыз да шуны раслый. Ул чакларда медицина шундый зур тизлек белән үсә алыр дип күз алдына да китермәгән идем. Мондый уңайлы шартларда үсмичә мөмкин түгел.

Ахыры 3 нче биттә >

Электрон ипотека популярлаша

Татарстанда күчемсез милекне рәсмиләштерү өчен электрон мөрәҗәгатьләр саны арткан. Ел башыннан бирле республикада ипотеканы теркәүгә 20 меңгә якын гариза тапшырылса, шуның 70 проценты – электрон рәвештә. Росреестрның Татарстан буенча идарәсе хәбәренә караганда, «24 сәгать эчендә электрон ипотека» проектыннан быел чама белән 10 мең кеше файдаланган инде. Ипотека алучыларның яртысы дигән сүз бу.

Росреестр идарәсе җитәкчесе урынбасары Лилия Борһанова әйтүенчә, электрон ипотека, Татарстанда яшәүчеләрне Күпфункцияле үзәк офисына барудан азат итеп, ипотека килешүен тиз генә төзү мөмкинлеге бирә. Моңа кадәр ипотеканы теркәүгә 5–7 көн таләп ителсә, әлеге проект вакытны бер тәүлектән кимрәккә калдыра. Шуңа күрә ипотеканы электрон рәвештә теркәүчеләр саны көннән-көн ишәя.

Хәзерге вакытта ипотеканың 70 проценттан артыгы электрон рәвештә теркәлсә, узган ел бу күрсәткеч якынча өчтән бер өлешен генә тәшкил иткән. Лилия Борһанова сүзләренә караганда, якын киләчәктә аны тулысынча электрон теркәүгә күчерү бурычы тора. Сүз уңаеннан, өлешчә килешүен теркәү өчен тапшырылган электрон мөрәҗәгатьләр саны да узган елдагы белән чагыштырганда 10 процентка үскән.

Абитуриентларга ярдәмгә

Вузларга Дәүләт хезмәтләре порталы аша гаризалар кабул итү сервисы эшли башлаган. Бу абитуриентларны документларын кабул итү комиссияләренә китереп тапшыру, чиратларда тору мәшәкатеннән коткара. Портал аша гаризаны дәүләт уку йортларына, шулай ук кайбер хосусый вузларга тапшырырга мөмкин.

Әлеге хезмәттән файдалану өчен, тиешле форманы тутырырга кирәк. Моның өчен порталда теркәлү шарт. Берьюлы биш вузга гариза тапшыру рөхсәт ителә. Уку йорты өстәмә документлар сораса, аларны да портал аша юлларга мөмкин.

Россия Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы хәбәренә караганда, сервиста абитуриентлар өчен файдалы күп кенә функцияләр булдырылган. Биредә өстәмә сынаулар вакытын белергә, конкурс исемлекләрендә үз урыныңны күзәтеп барырга, шулай ук вузның кабул итүенә ризалык бирергә мөмкин. Укырга кергәч, уку йорты портал аша хәбәр җибәрәчәк.

Өченче тыныч атна

Соңгы тәүлектә Татарстанда 68 кеше коронавирус йоктырган. 21е хастаханәгә салынган. Пандемия башланганнан бирле республикада COVID-19 инфекциясен иярткүнең барлыгы 152020 очрагы расланган. 147827 кеше савыккан, шул исәптән 32се – соңгы тәүлектә. Республикада инде менә өченче атна рәттән ковидтан үлем-китем очраклары күзәтелми.

Гомумән, Россиядә бер тәүлек эчендә 2667 кеше чир йоктырган.

Яңгыры да, кояшы да булыр

Татарстанда артык эссе дә, суык та булмаган, явым-төшемле һава урнашты. Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, температура күпьеллык уртача күрсәткечләр аралыгында тирбәлә. Чәршәмбегә кадәр республикада урыны белән яшенле яңгырлар көтелә, шул ук вакытта һава температурасы әкренләп күтәрелә. 22 июньдә көндез +21…+26 градус булса, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә +28 градуска кадәр эссе фаразлана.

Башлангыч мәгълүматларга караганда, ял көннәрендә – 25–26 июньдә – республика антициклон йогынтысында калып, явым-төшем тукталачак. Төньяктан искән җил салкынчарак һава алып килә: шимбә көнне җылылык +19…+24 градустан артмаячак. Якшәмбедә исә термометрның терекөмеш баганасы +21…+26 градусны күрсәтәчәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яшәеш

Төзек булсын өчен түлисе

Июль, елдагыча, яңалыктан башланачак. Гадәттәгечә, ай башыннан коммуналь хезмәтләр өчен тарифлар үзгәреш кичерәчәк. Ул бигрәк тә башкала халкы өчен сизелерлек булачак.

1 июльдән бөтен Россия буенча коммуналь хезмәтләргә (газ, электр энергиясе һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итү) тарифларны үзгәртү ниятләнә. Татарстанда бу түләүләр уртача алганда 6,2 проценттан да артмас дип ышандыралар. Казанда бу күрсәткеч 13 проценттан артмаска тиеш. Республикада яшәүчеләр яңа тарифлар буенча исәпләнгән квитанция кәгазьләрен август аенда алачак.

Бәя үзгәреше сәбәпсез түгел. Әйтик, Казанда су һәм канализация торбаларының 70 проценты тузган. Бу инде аварияләр санына да тискәре йогынты ясый. Узган ел 96 очрак булса, 2022 елның соңгы айларында гына да 80нән артып киткән. Казандагы су һәм канализация торбаларының гомуми озынлыгы – 3 мең чакрым тирәсе. Ел да тикшереп, төзекләндереп торсалар да, барысын да колачларга мөмкинлек җитми. Тулаем яңарту эшләре өчен иң кимендә 40 млрд сум акча кирәк. Моңа исә бюджеттан акча каралмаган.

Сүз уңаеннан, Татарстанның коммуналь инфраструктурасын узган ел 5,7 млрд сумга тәэмин иттеләр. 2022 елда әлеге сумма 2,5 тапкыр – 13,9 млрд сумга кадәр арттырылды. Шуның 9 млрд сумын бюджеттан тыш чыганаклардан табарга тиешләр.

Коммуналь хезмәтләргә тарифны арттыру хисабына алынган акчаны Чистай, Парин, Имәнлек, Ершов, Гудованцев, Восстание, Кызыл Кокшай урамнарындагы, Ямашев проспектындагы магистраль коллекторларны төзекләндерүгә тотачаклар. Шулай ук Гадел Кутуй, Толстой, Ломжа, Назарбаев, Кол Гали, Декабристлар, Мәүлетов, Гладилов, Серов, Щапов, Архангельск һәм Дорожная урамнарында су торбаларын ремонтлау күздә тотыла.

– Казанда миллионнан артык кеше яши. Бүтән калалар белән чагыштырып караганда, тарифлар буенча без – 14 нче урында. Мәскәү, Түбән Новгород, Ростов-Дон, Волгоград, Уфа, Воронеж бездән алдарак тора, – ди башкаладагы «Водоканал» җәмгыятенең директор урынбасары Таһир Вәлиев.

БАШКАЛАДА ТАРИФЛАР

Хезмәт	Ничә сум булачак?
Табигый газ	6,25 сум/куб.м
Газ плитәсе булган фатирларда электр энергиясе	1 кВт/сәг өчен – 4,30 сум
Электр плитәсе булган фатирларда электр энергиясе	1 кВт/сәг өчен – 3,20 сум
Күпфатирлы йортларда яшәүчеләр өчен каты көнкүреш калдыклары белән эш итү	99,93 сум (1 кешегә)
Шәхси йортларда яшәүчеләр өчен каты көнкүреш калдыклары белән эш итү	108,40 сум (1 кешегә)
Су белән тәэмин итү	24,8 сум/куб.м
Су чыгару	27,6 сум/куб.м.

Сүзгә-сүз



Ринат ФӘХРЕТДИНОВ, катнаш көрәш буенча UFC бәйгесендә чыгыш ясаган беренче татар спортчысы:

Кызганыч, татарлар Татарстанда гына яши дигән ялгыш фикер бар. Татарлар республикадан читтә дә күп. Без Россия, дөнья буенча таралган. Без бердәм булып яшәргә тиеш. Безне бүлгәләргә кирәкми. Үземнең милләтемне көрәш дөньясында популярлаштырырга тырышам.

(«Татар-информ»)

ТАТАРСТАНДА – ЭШКУАРЛЫК

Быелның 5 аенда Татарстан Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Фәрит Габделганиев исеменә республика эшкуарларыннан 1508 мөрәҗәгать килгән. Аларның 70 проценты буенча эшкуарларның мәнфәгатьләрен яклый алганнар. Калганнары буенча хокукый киңәш бирелгән.

ЭШКУАРЛАРНЫ НИ БОРЧЫЙ?

Дәүләт һәм муниципаль органнар белән бәхәс	25%
Хуҗалык итүче субъектлар арасындагы бәхәс	15%
Салым мәсьәләләре	14%
Ярдәм чаралары	13%
Банклар белән аңлашылмаучанлык	12%



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КОТКАРУ ТӘГӘРМӘЧЕ

Дөньякүләм киеренкелек һәм икътисади түнтәрелеш, кызганыч, дәвам итә. Рекордлы инфляция кагылмаган бер генә ил дә калмады диярлек. Иң аянычы: килеп туган вазгыятьтән чыгу юлы юк. Инфляцияне авызлыклыйм дип, әйләнештәге акчаларны җыеп ала башласаң, фонд базарлары ава. Аларны коткарыйм дип, акча басуны дәвам иттерсәң, халык бәяләр күтәрелешенә чыдый алмый. Энергия чыганакларына бәяләр үсеше болай да инде чыдый алмаслык дәрәҗәгә якыная. Ял көннәрендә Лондонда протест маршы үтте. Халык Премьер-министр Джонсонны тәнкыйтьли, «Сугышны туктатыгыз, муллыкны түгел!» дигән плакатлар күтәргәннәр иде. Сәясәтчеләр халык ачуын Украина тирәсендәге вазгыятькә юнәлтергә тырыша. Газ һәм нефтьнең бәяләре чамасыз күтәрелүдә Кремль башлап җибәргән махсус хәрби операцияне сәбәп итеп күрсәтәләр. Петербургтагы икътисади форумда Путин бу уңайдан: «Россиянең махсус хәрби операциясе Көнбатышка барлык проблемаларында Россияне гаепли торган «коткару тәгәрмәче»нә әйләнде», – диде. Кремль лидеры дөрес билгеләп үтә: газга бәяләр күтәрелеше 24 февральдән күптән алда башланган иде. Украина конфликты гигант инфляциягә сылтау буларак оештырылды, Путин сүзләре белән әйтсәк: «Россияне ул конфликтка өстерәп керттеләр».

Иң начары шул: илләр конфликтны чишү түгел, катлауландыру һәм Бөтендөнья сугышына кадәр үстерү юнәлешендә эшли. НАТОның Генераль секретаре Йенс Столтенберг: «Украинадагы сугыш (алар сугыш дип атыйлар, Мәскәү терминологиясен кабул итми) берничә елга сузылырга мөмкин», – дип фаразлады. Британия армиясе Генераль штабының яңа җитәкчесе Патрик Сандерс: «Минем гадәттән тыш вазыйфам – безнең армиябезне никадәр мөмкин булса, шулкадәр үлем китерүче һәм нәтиҗәле итү. Вакыт җитте, һәм без ул мөмкинлектән файдалана алабыз. Өченче Бөтендөнья сугышында сугышырга һәм Россияне җиңәргә әзерләнегез», – диде. Генераль штабка әле яңа гына (июнь) аенда шундый сугыш карчыгасын билгеләүләре британиялеләрнең, чынлап та, зур сугышка әзерләнүен хәбәр итә. Россияне НАТО белән турыдан-туры конфликтка тартып кертергә тырышучылар бик астыртын эш итә. Литва тимер юллары Калининград өлкәсенә һәм аннан Россиягә санкцияләргә эләккән товар транзитын туктау турында игълан иттеләр. Бу өлкәне бик авыр хәлгә куя. Өлкә губернаторы Антон Алиханов: «Төбәкне икътисади яктан буу омтылышы», – дип бәяләде әлеге адымны. Товарларны диңгез юлы аша ташырга туры киләчәк, әмма бу юл 50 процентка кыйбатрак. Россия сәясәтчеләре, Литва халыкара законнарны боза һәм моның өчен җавап бирергә туры киләчәк, дип саныйлар. Вазгыятьне хәрби бәрелешкә җиткермәү мөһим. Әмма НАТО һәм АКШ көчләренең элекке башкомандующие Уэсли Кларк: «НАТО Украинадагы хәрби вазгыятькә катнашырга тиеш», – дип белдерә. Капитализмның гомуми кризисы көчәйгән саен, зур конфликт куркынычы арта. Бөтен өмет – Мәскәүнең акыллы сәясәт алып баруында һәм Көнбатыш өчен «коткару тәгәрмәче»нә әйләнми калуында.

Россиядә

РУПИЯ ҺӘМ ЮАНЬНАРНЫ НИШЛӘТЕРГӘ?

Россиянең эчке икътисади тормышында вазгыять шатланырлыкмы, көенерлекме икәнен әлегә аңлау кыен. Икътисади үсеш министрлыгында июнь аенда илдә бәяләр төшүе – дефляция башланрыга мөмкинлеген әйттеләр. Әйе, әйе, икътисади яктан нык алга киткән Көнбатыш илләрендә инфляцияне нишләтергә белмәсәләр, бездә – дефляция. Бәяләр төшү – капитализм классик кризисының билгесе ул үзе. Көнбатышта элек гел шулай була иде: кризис башландымы, бәяләр төшә. Россиядә бу вазгыять, әгәр тормышка аша калса, беренче тапкыр. Үткән елларда Байден велосипедтан егылды бит. Аны, мәзәк итеп, АКШ лидеры долларны 60 сумга алып булуын ишетеп егылды, диделәр. Әмма вазгыять көлке түгел. Доллар һәм евро Россия өчен кыйммәтен югалткан валюталарга әйләнеп бара. Экспорт өчен Көнбатыш безгә үз валютасы белән түли, әмма импортка товар бирүне бик нык чикли. Акча бар – товар юк вазгыяте илне кыен хәлгә куя. Петербургтагы форумда Путин: «Ә нигә товарларны доллар һәм еврога алыштырырга?» – дип сорау куйган икән, бу аптыраган үрдәкнең күлгә арты белән чумуы кебегрәк инде. Әйе, доллар һәм евродан башка да сәүдә итеп була. Кытай, мәсәлән, безнең чималга бик рәхәтләнеп юань белән түли. Һиндстан бездән нефть һәм ташкүмер сатып алуны дистәләгән тапкыр арттыра һәм рупияләрне бер дә кызганмый. Ахыр чиктә Дәһлидә күпме теләсәләр, шуның кадәр рупия баса алалар, Пекинда юань өчен кәгазь җитәрлек. Бу эшнең – милли валюталарга товар сатуның тәмен дәүләтләр шулкадәр татып өлгерде: Филиппинда Россия нефтен песога сатуны таләп итәләр. Филиппин песосына нәрсә алып була? Бик аз нәрсә. Һәм бары тик Филиппиннан гына. Төрекләр дә, пакьстанлылар да, гарәпләр дә, хәтта Латин Америкасы илләре дә безгә песога гына түгел, рупиягә дә берни дә бирмәячәкләр. Хәтта Һиндстан үзе дә барлык безгә биргән рупияләргә товар биреп бетерми. Санкцияләргә кадәр үк Россия ул илгә товарны үзе сатып алганнан 4,7 миллиард долларга күбрәк озаткан. Хәзер энергия чыганакларын Һиндстанга озату 31 тапкыр арткан. «Дус ил»ләр Россия чималын 30 процентка кадәр дисконт белән, ягъни арзангарак алалар һәм безгә сатканда санкцияләр режимын бик төгәл үтәргә тырышалар: исемлеккә кермәгән товарлар белән генә сәүдә итәләр. «Параллель импорт» белән алардан кайтарылган технологик продукциянең байтак өлеше Россиядә эшләми. Телевизорлар күрсәтми, смартфоннар программа яздырмый. Менә бит эш кая таба бара!

«Дус ил»ләр белән дә ара бик тиз бозылырга мөмкин. Казахстан һәрвакытта да санкцияләрне төгәл үтәвен әйтеп килә. Җитмәсә, Токаев Петербургтагы форумда Путин янәшәсенә утырып, ДНР белән ЛНРны «квази-дәүләтләр» дип атады һәм аларны танырга җыенмавын белдерде. Россия казах нефтен үз портлары аша сатуны чикләде, Астана Россия ташкүмере төялгән вагоннарны тоткарлады.

Нәбиуллина экспорт – импорт мәсьәләләренә башка күзлектән карарга чакырды. Экспорт бар, импорт юк икән, нигә сәүдә итеп торырга? Товарларны күбрәк эчке базарга җитештерергә. Үзәк банк рәисе шул фикерне куәтли.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Төркия белән хезмәттәшлек юллары барланды, туризм тармагын үстерү юнәлешләре билгеләнде. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның кичәге көндәлегендә шундый мөһим мәсьәләләр урын алды. Татарстан Президенты Казан Кремлендә эшләүче күргәзмәләр белән дә танышты.

tatarstan.ru

Халыкара хезмәттәшлек

Рөстәм Миңнеханов Төркия Сәнәгать һәм технологияләр министрлыгы делегациясе һәм «Гебким» оешкан сәнәгать зонасы җитәкчелеге белән очрашты. Ул Төркия делегациясенең Татарстанга эш сәфәре кысасында узды. Сәфәр барышында кунаклар «Алабуга» махсус икътисади зонасы, КамАЗ эшчәнлеге белән дә танышты.

Президент Россия белән Төркия арасындагы стратегик хезмәттәшлекне билгеләп үтте. «Бу безгә Татарстанда да, Төркиядә дә проектларны үстерү буенча актив эшләргә мөмкинлек бирә. Барлык кыенлыкларга карамастан, узган ел безнең товар әйләнеше 560 млн доллардан артып киткән. Миңа калса, бу сан күбрәк булырга да мөмкин», – диде ул.

Төркия инвесторларына ышанычлары өчен рәхмәт белдереп, Рөстәм Миңнеханов Татарстандагы барлык заводларның уңышлы эшләвен билгеләп үтте. Саннар теленә күчсәк, Төркия оешмалары республикага якынча 2,5 млрд доллар инвестиция керткән.

«Без чын күңелдән элемтәләребезне киңәйтү яклы. Һава элемтәсе, безнең муниципалитетлар арасында хезмәттәшлек – болар бар да уртак эш өчен мөмкинлекләрнең зур булуын күрсәтә. Татарстанда яңа проектларны гамәлгә ашыру өчен кызыклы мәйданчыклар күп», – диде республика җитәкчесе.

Туризм

Яңа проектлар дигәннән, якын киләчәктә Татарстанда яңа туризм кластерлары да пәйда булачак. Билгеле булганча, быелның мартында Татарстан белән «Туризм РФ» корпорациясе акционерлык җәмгыяте арасында килешү төзелде. Аның нигезендә «Соколка», «Свияга», «Кама Тамагы», «Лаеш» һәм «Идел Болгары» дип исемләнгән биш туристик кластерны үстерергә уйлыйлар. Соңгысы «Идел сәяхәте» ширкәте составына кертелгән. Аның ярдәмендәге Идел буе федераль округының тагын алты төбәгендә туристлар санын арттырып, әлеге тармакны үстерергә җыеналар.

Кичә Рөстәм Миңнехановның «Туризм РФ» корпорациясе акционерлык җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары Денис Секачев белән очрашуы барышында да шул хакта сөйләштеләр. Очрашуда туризм тармагында хезмәттәшлек, эчке туризмны үстерү турында да фикер алыштылар.

Тарих

Кичә Рөстәм Миңнеханов Казан Кремле тарихы музееның сәнгати проектын эшләү буенча тәкъдимнәр белән танышты. Биредә тарихи иконография, макетлар, документаль һәм архив материаллары кулланылачак. Проект авторлары дивар һәм идәннәрне ничек бар – шул килеш саклап калырга тәкъдим итә. Бу фикерне Татарстан Президенты да хуплады. «Әлеге уникаль киңлекнең тарихи йөзен, биредә булган рухны мөмкин кадәр саклап калырга кирәк», – диде ул һәм барлык кисәтүләрне исәпкә алып, проектны эшләп бетерергә кушты.

Аннары Рөстәм Миңнеханов Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган «Иман нуры яктысы» күргәзмәсен дә карады. Әйдәп баручы фәнни үзәкләр, музей һәм китапханә фондлары тарафыннан әзерләнгән күргәзмә проекты 922 елда Татарстанда булган вакыйгаларның иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни әһәмиятен искәртә. Күргәзмәдә сирәк кулъязмалар, китап ядкарьләре, Болгар һәм Алтын Урда чоры тәңкәләре, намаз келәмнәре һәм хатын-кызлар костюмнары, каллиграфик композицияләр, борынгы зәркән бизәнү әйберләре белән гамәли сәнгать әсәрләре тәкъдим ителгән.

Рөстәм Миңнеханов «Милли кием театры» проекты белән дә танышты. Экспозициядә яңадан торгызылган тарихи костюмнар, бизәнү әйберләре урын алган. Татарстан Президентына бина ишегалдын үстерү планын да тәкъдим иттеләр. Аның нигезендә биредә туристлар өчен ял итү зонасын төзекләндерү, төрле чаралар оештыру өчен шартлар булдыру күздә тотыла.

САКЛА, ВАТЫЛМАСЫН!

АТТРАКЦИОННАРНЫҢ БЕРДӘМ БАЗАСЫН ЯСАРГА ҖЫЕНАЛАР

Яңалык

Бер генә бәйрәмне дә алардан башка күз алдына китереп булмый хәзер. Сүз артист, җырчы, алып баручылар хакында түгел, ә инде бизнеска әверелгән күңел ачу чаралары – батут, карусель, төрле аттракционнар турында бара. Аларның бердәм базасын булдыру турында уйланалар. Бу аттракционнарның төзеклеген дә, закон кысасында эш алып баруын тикшерү өчен дә кирәк.

Аттракционда төрле тән җәрәхәтләре алган, имгәнгән дигән хәбәрләрне еш ишетергә туры килә. Кызганыч, күңел ачу дигәндә куркынычсызлык мәсьәләсе онытылып тора шул. Ул күңел ачу шәп кенә табыш китерсә, бигрәк тә. Мәсәлән, Омскида бер ханым аттракционга утырган җиреннән егылып төшкән, Волгоградта бер үсмернең гомере тарзанкада атынганда өзелгән. Башка шәһәрләрдә дә шундый очраклар аз түгел.

Россиядә 15 меңләп механикалаштырылган аттракцион эшли. Шунысы кызык та, кызганыч та: аларның куркынычсызлыгы өчен берәү дә җаваплы булмаган икән. 2018 елда, махсус закон кабул ителгәч кенә, төбәк хакимияте бу вазыйфаны үз өстенә алды.

Заманасы үзгәрү белән, күңел ачу аттракционнары да үзгәрә. Кәттә, гаҗәпләндерерлек, кызык кына булсын!

Россиянең парк һәм аттракцион җитештерүчеләр ассоциациясе вице-президенты Игорь Родионов сүзләренә караганда, хәтта чит ил санкцияләре дә бу төр индустриягә әллә ни йогынты ясамаган. Тик ихтыяҗ гына аз: илдә ел әйләнәсе эшли торган күңел ачу парклары юк дәрәҗәсендә чөнки. Халыкта аттракционнарга йөрү культурасы да тәрбияләнмәгән.

Билгеле, аттракционнарның кагыйдәләре, техник регламенты була. Кызык эзләүчеләр белән акча эшләргә теләүчеләргә карата да контроль бар, димәк. Әйтик, судагы күңел ачу чаралары (катамаран, «банан») өчен кечкенә суднолар буенча дәүләт инспекциясе җаваплы. Пляж өчен прокатка бирелә торган күңел ачу чараларын контрольдә тоту – Роспотребнадзор җилкәсендә. Яр буена зур аттракционнар урнаштырылса, дәүләт техник күзәтчелек идарәсе эшкә җигелә. Аттракционнарда катнашучылар белән ул-бу килеп чыкмасын, тәртип саклансын өчен күңел ачу чарасы янына махсус күзәтүче куюны сораулары да гаҗәп түгел.

Тиздән барлык аттракционнарны да бердәм федераль базага берләштерәчәкләр. Махсус онлайн хезмәт әзерләнә инде. Аттракционнарның закон нигезендә эшләвен җаваплы түрәләр дә, гади халык та тикшерә алачак. Бу хезмәт ярдәмендә аттракционның техник куркынычсызлыгы, соңгы тапкыр тиешле органнар тарафыннан кайчан тикшерү узганлыгы һәм башка төр мәгълүматны

kzn.ru

белергә мөмкин булачак. Онлайн ярдәмчене быел эшләтеп җибәрергә җыеналар. Теләсә кайда, теләсә нинди аттракционнарда күңел ачканчы, монысы тагын бер кат уйланырга мәҗбүр итәр, шәт.

ИТЕ ШӘП – ҖИТКЕРЕП БУЛМЫЙ

Авыл хуҗалыгы

Күпчелек очракта журналистны кызыксыну йөртә. Бу юлы да Мөслим районының Тамьян авылында гадәти булмаган токымлы сарыклар асраганнарын ишеткәч, аларның үзләрен күреп, хуҗалары Айдар Шакиров белән танышып чыгасы иттек.

– Мин яшь вакытта Әфганстанда хезмәт иттем, – дип искә алды Айдар Шакиров эш башлап җибәргән елларын. – Анда курдюклы сарык итен ашап, бик яратып калган идем. Ул елларда әти-әни гадәти сарык асрый иде, тик мин менә шундый токымлы сарыклар үрчетү теләге белән яна башладым. 1993 елларда, КамАЗда эшләгән чакта, Казахстаннан өч сарык, бер тәкә алып кайттым. Ул вакытта якын-тирәдә мондый токымлы сарыклар беркемдә дә юк иде.

Дөрес, баштарак, әлеге сарыклар безнең климатка яраклаша алмаячак, алар ирек, дала ярата, үрчетә алмассың, дип шик белдерүчеләр дә табыла. Тик Айдар абый башлаган эшен ярты юлда ташлап калдыра торганнардан булмый. Алып кайткан маллары үрчи, яңалары кайта тора. Шулай итеп, бүген аның сарыклары 500 башка җиткән.

«Бу кадәрле малны кайларга куеп бетерәсез?» – дип кызыксынуыбызга каршы ул: «Җиткереп булмый әле аны, – диде. – Шашлык өчен бик яратып алалар. Корбанга да күп сорыйлар. Күрше-тирә районнардан токымга дип тә алып китәләр. Мондый сарыкларның ите сусыл, йомшак була. Ите дә, мае да авызда катып китми. Курдюк мае файдалы, төрле

Илдар Мөхәммәтҗанов

витаминнарга бай һәм кыйммәт йөри. Аны кушып ясаган ризыклар бик сусыл килеп чыга. Майны аш-су әзерләүдән тыш, медицинада, косметологиядә киң кулланалар. Май сарыкның арт санына җыела һәм хайванның симезлеген шуңа карап билгеләп була. Бөтен төр ит арасында кеше организмы өчен иң файдалысы – сарыкныкы. Сарык итенең бәһасе генә юк. Бер абзый ел да Германиядән кайткан балалары-оныклары соравы буенча, сарык сатып ала. «Ник тегендә алып ашамыйсыз?» – дип сорый икән балаларыннан. Тегеләре исә: «Германиядә бик кыйммәт бит ул», – дип җавап бирәләр икән. Ә бездә аның тиресен дә алучы юк, ташлыйбыз. Ә бит заманында аңа чират торалар иде».

Бер яшьлек сарык 24 кг ит бирә икән.

– Гадәттә көтүгә өч тәкә йөри. Шуларның берсе – лидер, калган икесе аңа буйсына. Сарыклар бер-берсен калдырып, ташлап китми. Лидерлары туктаса – туктыйлар, ул ашаса – ашыйлар. Токымлы тәкәләрне берничә районнан 25–30 мең сумга алып кайтам. Токымлы тәкәгә әйләнгәнче, бәрәнне башта үстерергә, аннары иң зурын, көчлесен сайлап алырга кирәк. Тәкә кимендә ике яшьлек булырга тиеш. Ул көтүгә җибәрелә һәм бераздан карт тәкәне алыштыра. Нәселне алыштырып тормасаң, сарыклар вакланып бетә, авырый башлый, – ди Айдар Шакиров.

Хуҗа сарыкларның ни дәрәҗәдә мөстәкыйль булуларын да сөйләп шаккатырды.

– Иртән капканы ачам да малларны иреккә чыгарып җибәрәм. Гади сарыклар көтүгә сәгать 6да чыга, минекеләр инде ул вакытка йөреп арып, тамакларын туйдырып, ял итәргә яткан була. Кич белән сәгать сигез-тугызда үзләре кайтып керә. Көтүче дә кирәкми. Күз-колак кына булып торам. Бәрәнләсә, анасы шунда кала. Бервакытта да бәрәннәрен ташлап китмиләр. Көн буе үзләренә нәрсә кирәк, шуның белән туклана алар.

Мал тоткан кешенең хуҗалыктагы эше бетәсе юк инде. Без килгән көнне дә, өстән коеп яуган яңгырга карамастан, хуҗаларның мәшәкатьле вакытлары иде. Хуҗабикәнең сарык йоны алган бер төркем ир-атны табын янынннан озатып, аласын алып, җыештырасын җыештырып йөргән мәленә туры килдек. Хуҗалар эшләп арысалар да, безне елмаеп каршы алып, өйләренә дәштеләр.

– Сарык йоны алу – бик мәшәкатьле эш, – ди Айдар абый. – Тулы бер система ул. Ир-ат көченнән башка берничек тә булмый. Йон ала торган машинаның авырлыгы гына да 4 килога якын бит аның. Алты машинага алты кеше тотына, калганнары малларны тотып тора, бер кеше талпаннарга, эчтәге суалчаннарга каршы прививка ясый. Бүген бездә, мәсәлән, ундүрт ир-ат эшләде. 140лап баш сарыкның йонын алдылар. Зур эшләрнең күпчелеген туганнар белән җыелышып эшлибез. Бу юлы да чит кешеләр аз иде. Аларга акча бирәбез. Кемнедер – итләтә, кемнедер баллата, печәнләтә бәхилләтәбез. Йонны елга бер генә тапкыр алабыз.

Тырышып эшләгәннең бәрәкәте була. Айдар Шакиров әнә шуңа инанган:

– Әфганстанга барып эләккәч, мондагы рәхәт тормыш әкият кебек кабул ителә башлады. Анда һәм монда бөтенләй башка дөнья. Шул вакытта мин: «Туган якларга шушыннан исән-сау әйләнеп кайтсам, тормышның, һәр көннең кадерен белеп яшәр идем», – дидем. Һәм әлегә кадәр шул кагыйдә буенча яшим дә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

СУГЫШ БАЛАЧАКНЫ АЯМАДЫ

Хәтер

Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасында сугыш чоры балалары белән очрашу булды. Бу чара «Җиңү волонтерлары» Бөтенсоюз иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк берлеге һәм Татарстан Республикасының балалар оешмалары советы белән бергәләп үткәрелде.

Балалар катнашында булгач, аңлашыла ки, очрашуның төп максаты да яшь буынга тарих сәхифәләрен җиткерү иде.

Сугыш чоры балалары дип аталган төркемгә 1928–1945 елларда туучылар керә. Сүз дә юк, мондый очрашулар элек тә еш булды. Әмма пандемия афәте бу күренешкә шактый зур үзгәреш кертте кебек. Моңа кадәр өлкәнрәк яшьтәгеләрнең, буе җитмәү сәбәпле «күтәртмә»ләр куеп, көне-төне станок янында эшләгәннәрен, басуда черек бәрәңге җыйганнарын, ачлык-ялангачлыктан җәфаланганнарын тыңларга туры килсә, бу юлы исә сугыш алдыннан гына яки сугыш вакытында туганнар җыелган иде. Алар арасында бердәнбер авыл кызы – Әтнә районы Олы Бәрәзә авылыннан Сәвия апа Шакирьянова бар. Калганнары – шәһәр кызлары. Игътибар белән тыңлап утыра торгач, авырлык бер булып килсә дә, аларның тормышлары тамырдан аерыла кебек тоелды миңа.

Эльвира ханым Крупина сугышның беренче көннәрендә үк Мәскәүдән кайткан. Аның әтисен 22 нче заводка парторг итеп җибәргәннәр. «Без аны бөтенләй диярлек күрмәдек тә. Вакыты шундый иде бит. Бу заводның бигрәк тә сугыш елларында нинди роль уйнаганын барыбыз да яхшы беләбез, – диде ул. – Мин үземне ачлыктан интектем дип әйтә алмыйм. Без бик дус, ярдәмчел булып яшәдек. Спорт белән шөгыльләндек. Барыбыз да җырларга яраттык. Безне шулай күңелсезләнмәскә, нык булырга өйрәттеләр. Музыка училищесын тәмамлагач, яслегә эшкә урнаштым. Аккордеонлы булу теләгем шундый зур иде. Шуны алу нияте белән 7 нче заводка эшкә кердем. Алдым мин аны. Шуннан бирле аерылганым юк. Ике балам, өч оныгым, дүрт оныкчыгым да музыканы үз иттеләр.

Миңа хәзер – 82 яшь. Бар кешегә дә бәхетле картлык телим. Өлкән яшьтәге кешеләрне бик хөрмәт итәм, яратам. Моңаеп утырмагыз. Үзем дә «Сәйдәш» мәдәният йортында «Волжанка» рус хорын җитәклим. Җәй көне теплоходларда туристларның күңелләрен ачам. Җырлаган кеше тиз картаймый», – дип саубуллашты ул һәм тиз генә репетициягә китеп барды.

Светлана ханым Кулагина сугыш башланганда балалар бакчасына йөри торган була. Беренче чиратта аның хәтерендә йөрәкләргә үтәрлек булып сирена улавы калган. «Бу хәрби өйрәнүләр иде, – ди ул. – Мин куркуымнан карават астына кереп кача идем. 1941нең көзендә Казанга Молдавиядән һәм Ленинградтан эвакуацияләнгән кешеләр килә башлады. Әнием дә бер гаиләне алып кайтты. Сугыш беткәнче бездә яшәделәр. Мин бик ябык идем. Шуңа күрә бакчада әйбәт ашатыла торган төркемгә күчерделәр. Какао бирәләр иде. Май белән сырдан ясалган бутербродны бүгенгедәй хәтерлим. Уенчыкларны катыргыдан кисеп ясадык. Аларны буядык. Бик матур килеп чыга иде. Марлядан тегелгән күлмәкләр киеп, госпитальләрдә чыгыш ясадык. Яралы сугышчылар безне бик хисләнеп тыңлады. Кайберләре күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып, елый да иде. Балаларын сагынганнар, күрәсең. Ашарга икмәк җитәрлек булмады. Шәһәр янында участоклар бүлеп бирделәр. Шунда бәрәңге үстердек. Тифтан бик курыктык. Аны эләктермәс өчен чисталык сакларга, гел юынып торырга кирәк иде. Сугыш башлануга сабын юкка чыкты. Урманга барып абага җыйдык та, аны яндырып, кечкенә шарлар әвәләдек. Аларны сабын урынына кулландык».

Римма ханым Гимадетдинова 1939 елны дөньяга килгән. Әмма ул сугыш елларын бик яхшы хәтерли булып чыкты. «Безнең тирәдә зенитчы кызлар яшәде, – дип истәлекләргә бирелде ул. – Бервакыт шулай башымны күтәреп карасам, баш очыннан гына фашист самолеты очып бара. Свастикасы бүгенгедәй күз алдымда тора. Әбием мине җитәкләп алды да тизрәк зенитчылар янына йөгерде. Соңыннан белдем: разведчик немец очкычының Казанга кадәр килеп җитү очрагы ике тапкыр булган икән. 9 Май көне дә бик истә калган. Мин бакчага үзем генә йөри идем. Ишек гел ачык була иде. Бу юлы ябык. Тарттым-тарттым – ачылмады. Шуннан бер абый килеп чыкты да: «Кызым, бүген Җиңү көне бит. Беркайда да эшләмиләр», – диде. Кайту юлына борылгач, мәйданга килеп чыктым. Анда халык җыелган иде инде. Гармуннар уйныйлар, җырлыйлар, бииләр.

oprt.tatarstan.ru

2010 елдан бирле Шәһәр ветераннар советында музейлар буенча куратор булып эшлим. Музей ул – үзе бер тормыш. Анда йөрү бик кирәк».

Тагын бер сугыш чоры баласы, Иҗтимагый палата әгъзасы Любовь Смирнова – 1944 елгы. Аңлашыла ки, ул күбрәк сугыштан соңгы вакыйгалар турында сөйләде, палатаның «Сугыш чоры балалары» бүлегендә эшләүче буларак, аның бүгенгесе дә шуңа бәйле.

Үзем дә авыл баласы булгач, Сәвия апаның чыгышын бигрәк тә көтеп алдым. Ул башта әтисе турында сөйләде. «Әтием Гаделшаны сугыш башлануга Суслонгерга җибәрәләр. Анда шартлар бик начар була. Барысы да фронтка китү турында хыялланалар. 1942 елны әтием дә китә. Смоленск өлкәсендә беренче бәрелештә үк һәлак була. Әнием 6 бала белән ялгыз кала, мин – иң кечкенәсе. Өлкәнрәк өч туганымны ФЗӨгә җибәрәләр. Киемнәр биргәч, азрак бушлай ашаткач, әнием дә каршы килми. Калган өч баланы аякка бастыру да бик читен була бит. Минем хәтердә ачлык, ялангачлык, хәерчелектән башка берни дә калмаган. Хәтта фотога да беренче тапкыр 10 яшьтә генә төшерә алганнар». Бераз гына тын торганнан соң, Сәвия апа болай диде: «Мин сугыш вакытында күргәннәремне яшьләргә сөйли башласам, алар ышанмыйлар. Шуңа күрә сөйләргә яратмыйм». Бу сүзләр үзе генә дә икмәк карточкасы күрмәгән, бер уч бодай өчен төрмәләргә утыртылган, черек бәрәңге ашап агуланган авыл халкының хәле чыннан да мөшкелрәк булганын күрсәтә кебек.

Ничек кенә булса да, Сәвия апаны авырлыклар сындыра алмаган. Ул бүген – «Җиңүнең көмеш волонтеры». «Көмеш волонтер» дигәннәренә 60 яшьтән өлкәнрәкләр керә икән. «Төрле чараларны бик күп үткәрәбез. Сәламәтлеге чикле балалар өчен спектакльләргә кадәр куябыз», – ди ул. Очрашу ахырында Сәвия апа белән гәпләшеп тә алдык. Мин аңа, йөрәк әрнүләрен кузгатса да, белгәннәре хакында яшьләргә җиткерергә киңәш иттем. Ул минем сүзләр белән килеште кебек.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

СЕЗ ИҢ КИРӘК КЕШЕ ИКӘНСЕЗ

tatarstan.ru

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Һәркайсының – үз батырлыгы

«Ак чәчәкләр» бәйгесендә катнашкан һәр табибның әнә шундый батырлыгы, тетрәнеп, кайчак җиңел сулап искә алырлык гыйбрәтле тарихы бар. Коронавирус дигән зәхмәт пәйда булгач, табибларның иң кирәкле, кадерле кеше икәненә инандык инде. Алар башкарган батырлыклар турында ишеткәч, бу фикернең хаклыгына тагын бер кат инанасың. «Уникаль очрак» номинациясендә җиңү яулаган Республика балалар клиник хастаханәсе табиблары коллективы йөрәге туктаган 5 яшьлек кызның гомерен саклап калган әнә.

Узган елның 7 ноябрендә Түбән Кама шәһәр балалар хастаханәсенә эче авырткан биш яшьлек Эвелинаны китерәләр. Кызның температурасы да күтәрелгән була, йөрәге минутына 200 тапкыр тибә. Икенче көнне аны Республика балалар клиник хастаханәсенә күчерәләр. Тикшерү барышында балага кискен миокардит диагнозы куела. 9 ноябрьдә Эвелинаның йөрәге кинәт туктап кала. Табиб-реаниматологлар ике сәгать буе баланың гомере өчен көрәшә. Әмма кызның гомере элеккечә үк кыл өстендә була. Йөрәкне күчереп утырту өчен аны һава борты белән Шумаков исемендәге трансплантология һәм ясалма органнар үзәгенә китерәләр.

Очыш вакытында, аппаратны гел контрольдә тотып, табиблар юл буе тезләнеп диярлек барган, теләсә нинди ялгыш хәрәкәт баланың гомерен өзәргә мөмкин

«АК ЧӘЧӘКЛӘР – 2022» РЕСПУБЛИКА БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ

НОМИНАЦИЯ	ҖИҢҮЧЕ
«Елның иң яхшы медицина хезмәткәре»	Ләйсән Анамова, Актаныш районы Аккүз авыл ФАПы фельдшеры
«Елның иң яхшы беренчел звено табибы»	Олег Наумов, Кама Тамагының үзәк район хастаханәсе табибы
«Уникаль очрак»	Республика балалар клиник хастаханәсе табиблары
«Сәламәтлек саклау тармагы легендасы»	Лев Козлов, ТАССРның атказанган табибы
«Ел табибы»	Роин Джорджикия, Татарстан һәм Россиянең атказанган табибы, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш белгече – йөрәк-кан тамырлары хирургы
Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның махсус бүләге – «Лада» машинасы	Рәзинә Мөгыйнова, Баулы районы Мортаза фельдшер-акушерлык пункты фельдшеры

булган. Операция кирәкмәгән, йөрәк эшчәнлеге акрынлап тернәкләнгән. Эвелина яңа тормышта беренче адымнарын ясаган. Шушы тарихны бәян иткән видеороликны карап бетергәч, сәхнәгә шушы табибларга рәхмәт әйтергә чыккан кечкенә генә кызчыкны күргәч, залдагы беркем дә күз яшьләрен тыеп кала алмады.

«Табибларга булган чиксез рәхмәтебезне сүзләр белән генә әйтеп бетерерлек түгел. Эвелина – яшәвебезнең мәгънәсе. Димәк, табиблар кызыбызның гына түгел, безнең гомерне дә саклап калган», – ди яшь аралаш сабыйның әнисе Ольга Зәйдуллина.

Шушы ук номинациядә катнашкан башка табибларның да каһарманлыгы алдында баш иярлек. Инсульт куркынычы янаган, гомере кыл өстендә булган ир-атка сигез сәгать буе операция ясап, гомерен саклап калган Чаллының Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе табиблары, коронавирус йоктырган йөкле ханымны коткарган Республика клиник хастаханәсе, 7 нче шәһәр хастаханәсе, Республика йогышлы авырулар хастаханәсе табибларына да авырулары гомере буе рәхмәтле булачак.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

2021 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 июнендә кабул ителде

1 статья
2021 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 355 194 302,5 мең сум һәм чыгымнар буенча 343 592 641,0 мең сум күләмендә, керемнәрнең чыгымнардан артуын 11 601 661,5 мең сум күләмендә һәм түбәндәге күрсәткечләре белән расларга:
1) әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;
2) әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары;
3) әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары;
4) әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары.

2 статья
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 18 июнь
№ 29-ТРЗ

Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

2021 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 июнендә кабул ителде

1 статья
2021 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 67 432 939,2 мең сум һәм чыгымнар буенча 67 096 048,9 мең сум күләмендә, керемнәрнең чыгымнардан артып киткән күләмен 336 890,3 мең сум итеп, түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:
1) Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганаклары буенча әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;
2) Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре буенча әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә;
3) Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары структурасы буенча әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә.

2 статья
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 18 июнь
№ 30-ТРЗ

Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 15 июнендә кабул ителде

1 статья
«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» 1998 елның 18 июнендәге 1661 номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2006, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 1^1 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:
«1^1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары федераль дәүләт фәнни оешмаларда, югары белем бирү федераль дәүләт мәгариф оешмаларында фәнни тикшеренүләр һәм (яисә) эксперименталь эшләнмәләр үткәрүне, федераль дәүләт фәнни оешмаларны үстерү программаларын яисә планнарын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итәргә, шулай ук әлеге фәнни оешмаларның инфраструктурасын булдыруда катнашырга хокуклы.».

2 статья
«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), аңа «тәэмин итәргә» сүзләреннән соң «, шулай ук югары белемнең уку- укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы федераль дәүләт оешмаларында югары белем алуны һәм бу оешмаларны үстерү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итәргә, шушы оешмаларның уку-укыту, җитештерү, социаль инфраструктурасын булдыруда катнашырга» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

3 статья
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 18 июнь
№ 31-ТРЗ

Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 15 июнендә кабул ителде

1 статья
«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 4 өлешенә (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш); 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), «, акцияләр» сүзен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2 статья
«Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), «, акцияләр» сүзен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

3 статья
«Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), «, акцияләр» сүзен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

4 статья
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 18 июнь
№ 32-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе башлыгы урынбасары – идарәнең лицензия-рөхсәт язуы бирү үзәге башлыгы, полиция полковнигы **Бламыков** Алексей Васильевич; граждан оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү, Татарстан Республикасында халыкны, территорияләрне һәм объектларны янгыннан саклауны тәэмин итү буенча чараларны тормышка ашыруга зур өлеш кертүе өчен Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе территориаль органы (Татарстан Республикасының кече суднолар буенча баш дәүләт инспекторы) җитәкчесе урынбасары **Венекдитов** Юрий Владимирович; финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге башлыгы **Газизҗанова** Миләүшә Мәгъсүмҗан кызы; халык сәламәтлеген саклау эшенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының академик В.М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Гурьянова** Татьяна Владимировна; һөнәри эшчәнлектә югары казанышларга ирешүе һәм нәтиҗәле хезмәте өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең үзкөйләнешле оешмалар өлкәсен контрольдә тоту (күзәтчелек итү) бүлеге башлыгы **Елесина** Гөлия Ринат кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры урынбасары – баш тикшерү идарәсе башлыгы, юстиция генерал-майоры **Изаак** Владимир Владимировичка **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Федераль ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хокукый эш, дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы **Сафина** Алсу Вазыйх кызына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Әгерҗе бүлеге башлыгы **Шәрипова** Юлия Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Зур Подберезье авыл җирлеге элекке башлыгы

ЧЕКМАРЕВ Федор Александровичның

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Казан

Башкала Сабан туе гадәттәгечә өч мәйданда – Тынычлык бистәсендәге Каенлыкта, Дәрвишләр бистәсендә һәм Аккош күле буендагы паркта узды. Бәйрәмдә 100 меңнән артык кеше кунак булган.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Казан мэры Илсур Метшин һәм Кемерово өлкәсе губернаторы Сергей Цивилев Тынычлык бистәсендә узган бәйрәмдә кунак булды. Биредә республиканың 11 районы үз ишегалдын оештырган. Кунакларның күңелен күрү белән бергә үз уңышлары белән уртаклашырга да тырыштылар. Әйтик, ике атна элек Кукмара терлекчеләре тәүлегенә 400 тонна сөт савып алуга иреште. Моңарчы булмаган күрсәткеч хөрмәтенә сөт чыгара торган каланча ясап куйганнар. Район ишегалдына керүчеләр әнә шуның янында рәхәтләнеп фотога төште. Кукмарада итекне дә шәп басалар, савыт-сабаның да сыйфатлысын ясыйлар. Кунакларга аларын да күрсәттеләр.

Алексеевск районы ишегалдында кунакларны кыңгырау чыңы каршы алса, Зәй осталары Казан читендә мунча күтәреп куйган. Ишегалдында исә балалар көрәшә. Рөстәм Миңнеханов, Минтимер Шәймиев, Илсур Метшин һәм Сергей Цивилев Менделеевск, Нурлат ишегалларында да кунак булды.

Төп мәйданда халыкны бәйрәм белән котлаганда Татарстан Президенты алдагы көнне генә Ульян өлкәсендә федераль Сабан туе узганын искә төшерде. «Бәйрәм илнең 58 төбәгендә һәм 35 чит илдә уза. Алары, бәлки, бу кадәр күләмле дә түгелдер, ләкин бөтен җирдә үткәрелә. Бу – халкыбызның үзенчәлеген, мәдәниятебезне күрсәтү өчен менә дигән мөмкинлек. Бу бәйрәм барыбыз өчен дә! Без барлык кунакларга (бүген безнең белән Төркия кунаклары да, Кемерово кунаклары да) бик рәхмәтле. Күп кенә шәһәрләр бүген биредә тәкъдим ителгән. Менә дигән мәйданчыкларны оештыручыларга һәм республика районнарына рәхмәт. Яхшы кәеф, уңышлар һәм илебезнең чәчәк атуын теләп калабыз. Республика өчен күп нәрсә эшләнгәне өчен Казанга рәхмәт. Бәйрәм белән!» – диде ул.

Кемерово өлкәсе губернаторы Сергей Цивилев Сабан туен үз иткәнен яшермәде. «Искиткеч бәйрәм бөтен ил буенча уздырыла. Әмма бу гына җитми – һәм ул чит илгә дә аяк баскан. Әле ике ел элек үк Рөстәм Миңнехановка шалтыратып, Кузбасста федераль Сабан туен уздыруны сораган идем. Ул миңа вакыты

tatarstan.ru

алдан ук билгеләнгәнен, бәйрәмне 2023 елда гына оештырып буласын әйтте. Бик сорагач, Татарстан Президенты шахтерлар Сабан туе уздырырга тәкъдим итте. Былтыр беренчесен оештырдык. Киләсе елда исә бездә шахтерлар Сабан туеның өченчесе һәм тәүге мәртәбә федераль Сабан туе да узачак. Бу бәйрәм кеше күңелен кызыклы, матур булуы белән генә түгел, ә тормыш кагыйдәләренә туры килүе – үз ватаныңа, гаиләңә, хезмәтеңә һәм балаларыңа карата мәхәббәт тәрбияләве белән дә яулап ала. Ата-бабаларыбыз васыять иткәнчә, бердәм гаилә булып яшәргә өйрәтә. Сабан туеның иң зур уңышы әнә шул», – диде Сергей Цивилев.

Тынычлык мәйданында баш батыр булып Кукмарадан Ринат Дәүләтшин танылды. Дәрвишләр бистәсендә Казаннан Айрат Фәтхуллин җиңү яулады, Аккош күле янындагы мәйданчыкта Булат Мусин батыр калды. Көрәшчеләргә тәкә белән квадроцикл бүләк иттеләр.

Казан башкарма комитеты хәбәр итүенчә, башкала Сабантуйларында 100 меңнән артык кеше кунак булган. Бәйрәм кунаклары бер тоннага якын чәкчәк, 1,5 тонна пылау, 650 кг шашлык, 23 мең порция туңдырма ашаган, 300 литрдан артык чәй эчкән. Ә мәйданда 1,5 меңнән артык артист чыгыш ясаган.

ТАТАРНЫҢ ҮЗЕ КЕБЕК

Чаллы

Автокалада Сабан туен 18 июньдә бәйрәм иттеләр. Шәһәр халкын һәм кунакларны котларга Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин килде.

Парламент башлыгы Яр буе паркына җыелган халыкны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм республика депутатлары исеменнән дә котлады.

– Быелгы бәйрәм аеруча зурлап оештырылган, көтеп алынган бәйрәмгә халык та күп җыелган. Чаллыда яшәүчеләрнең горурланырлыгы бар: алар республика икътисадына, социаль һәм мәдәни үсешенә зур өлеш кертә, – диде ул. – Санкцияләр аркасында барлыкка килгән авыр шартларда Чаллыда яшәүчеләргә дә җиңел түгел. Әмма алар бу хәлдән чыгу юлын таба. Шәһәр җитәкчелеге һәм оешмалар бергәләп барлык мөмкинлекләрдән файдаланырга тырыша. Шул рәвешле күпмилләтле Татарстанда бергәләп эшлиләр һәм бәйрәмне матур итеп каршы алалар.

Быелгы бәйрәмнең баш батыры булып Ранис Гыйлаҗетдинов танылды. Төп алышта ул Эльдар Хәмитовны отты һәм «Лада Веста» машинасына ия булды.

Минзәлә

Узган шимбәдә Татарстандагы ун дәүләт театры артистлары үзара көч сынашты, тамашачының да күңелен күрде. Минзәләдә XIV Театрлар Сабан туе узды.

Бәйрәм театр коллективларының традицион парады белән башланып китте. Сабантуй мәйданыннан республика күләмендә танылган, тамашачыларның иң яраткан театрлары – Камал, Тинчурин, «Әкият», Кариев, Чаллы драма театры, Чаллы курчак театры, Минзәлә, Түбән Кама, Әлмәт, Әтнә театры коллективлары үтте. Ачылыш тантанасында кунакларны район башлыгы Айдар Сәлахов сәламләде.

– Театр сәнгате ул мәңгелек. Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай теле белән әйткәндә: «Театр яктылыкка, нурга илтә. Кире юлга җибәрми, уңга илтә». Сез мондый чаралар белән киләчәк буыннарны тәрбияләүдә, гореф-гадәтләрне, традицияләрне саклауда зур көч куясыз, – диде ул.

Татарстанның мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры директоры Фәнис Мөсәгыйтов та катнашучыларга ихлас теләкләрен җиткерде. Ачылу тантанасында республиканың театраль Сабан туе әләмен узган елгы көрәш батыры, Минзәлә театры артисты Нәфис Гайнуллин күтәрде.

Театрлар Сабан туе, гадәти Сабан туеның бөтен шартын китереп, милли бәйрәмнең барлык традицион уеннары белән узды. Артистлар 13 төрле ярышта үзләрен сынап карады. Театр артистлары һәм хезмәткәрләре милли көрәш мәйданында бил алышудан тыш, волейбол уенында (анысы быел беренче тапкыр узды) һәм бию марафонында катнаштылар. Мәйдан ду килде, әллә ничәгә бүленеп, һәр почмакта уеннар башланды. Берсендә таяк тартыштылар, икенчесендә капчык киеп, агач кашыкка йомырка салып йөгерделәр, башкаларында чиләк-көянтә белән су ташыдылар, капчык белән сугыштылар,

tinchurinteatr.ru

кул көрәштерделәр, чүлмәк ваттылар, гер күтәрделәр. Артист халкы, шау-гөр килеп, беренчелек өчен көрәште, кыскасы.

Барыннан да бигрәк аркан тарту ярышы кызу барды. Янып-пешеп аркан тарткан хезмәттәшләре өчен артистлар да, тамашачылар да көч биреп торды. Нәтиҗәдә Минзәлә театрында эшләүче хатын-кызларны бер дәүләт театры да уздыра алмады. Алар инде 14 нче тапкыр беренчелекне беркемгә дә бирми.

Капчык киеп йөгерү, авыш колгага менү, чүлмәк вату кебек традицион уеннардан тыш, артистлар бию марафонын ярата. Һәр театрдан берәр пар сәхнә түрендә берьюлы төрле музыкага биеде. Биюдән соң бер пар төшеп кала барды. Жюри әгъзалары җиңүче итеп Тинчурин театрын билгеләделәр, икенче урынга – Минзәлә, ә өченче урынга Камал театры артистларын куйдылар.

Милли бәйрәмебезнең күрке саналган көрәш Сабан туеның иң мавыктыргыч өлеше булды. Артистлар арасында да оста итеп көрәшүчеләр бар икән. Баш батыр исеме өчен Минзәлә театрыннан Илназ Хисмәтуллин һәм Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачылар театры артисты Муса Камалов көрәште. Нәтиҗәдә Муса өстен чыкты. Батырга башка елларда тәкә һәм автомобиль бирелсә, быел тәкәгә өстәп, суыткыч бирелде.

– Әлегә нәрсә булганын үзем дә аңлап бетермим. Сабан туена килеп, көрәштә катнашкач, җиңүне көтәсең инде ул, тик батыр калырмын дип уйламыйсың. Әйбәт килеп чыкты, шөкер. Оештыручыларга бик зур рәхмәт. Тәкә безнеке! – диде Муса.

Быел төп бүләк – машина Сабан туе батырына түгел, ә ярышларда иң күп балл җыйган театрга бирелде. Ярыш нәтиҗәләре буенча, өченче урынга Галиәсгар Камал театры чыкты, икенче урынны Габдулла Кариев исемендәге яшь тамашачылар театры һәм Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә театры алды. Беренче урынга Кәрим Тинчурин театры командасы лаек булды. Алар Театрлар Сабан туеның төп бүләге – «Лада-Веста» автомобиле белән бүләкләнде.

Ләйсән САФИНА

Ульян

Берләштерә, дуслаштыра, ерак араларны якынайта. Илнең төрле почмакларында яшәүче татарларга танышырга, очрашырга, зурдан кубып бәйрәм итәргә тагын бер җай чыкты. Ульян каласында XXII Федераль Сабан туен гөрләтеп кайттык. Бәйрәм мизгелләре – безнең репортажда.

Күңелең киң булгач, бәйрәм итәргә дә бер генә көн җитми шул. Ульяндагы бәйрәм дә 17–18 июнь көннәрендә гөрләде.

Иң беренче эш итеп һәм традицияләренә туры китереп, атлар узышты. Чабышларда катнашыр өчен барлыгы 100дән артык гариза килгән.

Берсеннән-берсе күркәм иде шул алар, чыннан да. Узышканнарын карарга халык та шактый җыелган иде.

Ат чабышында җиңүчеләргә әзерләнгән призлар да саллы иде. Әйтик, Ульян өлкәсе губернаторының махсус призын отучыга – 1,2 млн сум, Бөтенроссия Сабан туе призына 1 млн сум тапшырылды. Җәмгысы – 5 млн сум күләмендәге акчалата бүләкләр.

Татарстан Республикасы призы өчен дә махсус чабыш уздырылды. Беренче булып Победоносец Лок кушаматлы айгыры белән Мәскәүдә яшәүче Раил Габдрәшитов килде. «Сабантуйлардагы чабышларда сирәк катнашабыз. Ешрак килергә кирәк икән! Күңелле монда», – диде ул, кулына җиңүче кубогы алганнан соң. Чабыш юлының бик үк шәп булмавын да әйтте ул, айгырга авыргарак туры килгән.

Дәү түбәтәйле, чәлпәкле һәм кәҗәле ишегаллары

Инде бәйрәмнең икенче көненә күчик. Федераль Сабан туе кунакларын чабышлар узган ипподромга һәм шәһәрнең Җиңү паркына дәштеләр. Янәшәдә урнашкан бу ике мәйданның буеннан-буена сату нокталары, чәй өстәлләре, Ульян өлкәсе районнарының һәм бәйрәмне оештыручыларның берсе булган, Татарстанны тәкъдим иткән Түбән Каманың ишегаллары тезелеп киткән иде. Кая гына барып төртелсәң дә, җырлашалар, биешәләр, бәйрәм белән котлашалар.

Иске Кулаткы районының ишегалдын еракלардан күреп алдык. Ник дигәндә, бер чатырларына 2,5 метр диаметрлы түбәтәй «кидереп» куйганнар. Шул түбәтәй әллә кайлардан чакырып тора. «Чынаякларыбызны күрегез – дүрт чиләк су сыярлык. Самавыры! Үзе борынгы, үзе зур». Лилия апа шулайрак каршы алды. Мактанырлыклары дәү түбәтәй белән дәү самавыр гына түгел: районда 20 җирлекнең 20се дә – татар авылы.

Ульян районы исә кунакларны онытылып бара торган татар халык ризыклары белән сыйлады. «Үзебезнең тутырган тавык та сирәк пешерелә бит, кызым. Кош теле, тасма, чәлпәк – ни генә юк табыныбызда», – дип сөйләп китте Рәдинә апа. Олы гына яшьтәге китапханәче ул. Сабан туена килеп, төрле төбәкләрдә сибелеп яшәүче татарлар белән аралаша, аларны менә шулай сыйлый алуларына ихластан сөенүен күз яшьләрен яшерә-яшерә әйтте...

Үзебезнекеләр – Татарстанны тәкъдим итүчеләр, ишегалды белән генә чикләнмичә, мәйданда тулы бер хуҗалык корып куйган иде. Берәүне дә битараф калдырмады ул – кайчан карама, кунаклар өзелмәде. Берәүләр экскурсия уздыручыны тыңласа, икенчеләр истәлек өчен фото «сукты». Түбәнкамалылар татарларның киң күңелен самавырда кайнаган чәй, шәп итеп ягылган мунча (кирәк кешегә себеркесе дә бар иде), тәмле телләрендә чагылдырырга тырышкан иде. Татарны бит мал-туарсыз да күз алдына китерү авыр. Шуңа да хуҗалыкта тавык-чебеш, тана, кәҗәләр белән тулы сарай да бар иде. «Кәҗәне 9 меңгә сатабыз, аласызмы әллә?» Сарайның нәкъ уртасында басып торучы малай шулай дип эндәште. «Алучылар бармы соң?» – дим. Кызыгып китүчеләр булган икән, бәйрәм беткәч, килеп алырлар инде, ди сабый. Алсалар, Сабан туеның менә дигән истәлеге булыр иде әле!

Матур кешеләр төбәге

Шушы ишегаллары буйлап йөргәндә, Пензадан килгән делегатлар белән дә сөйләшеп алырга җай чыкты. Сүз уңаеннан, федераль Сабан туена Россиянең 52 төбәгеннән кунаклар килгән иде.

– Шулкадәр матур бәйрәм, әйтеп кенә аңлата торган түгел. Мондый чараларның Россия буйлап сибелеп яшәүче татарлар өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын әйтеп тә торасы юк. Күңел ачар өчен генә түгел, очрашып, аралашыр өчен киләбез. Милләттәшләребезнең тәҗрибәсен үзебезгә алып кайтып китәбез, – дип сөйләде Пензадагы «Ак калфак» татар хатын-кызларының төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Эльмира Васильева.

Бәйрәм генә түгел, Иделнең киң кочагына сыенып яшәүче Ульян халкына да гашыйк булган алар. Татарстанның Чүпрәле районында туып, бүген Ульянда гомер итүче Фәридә апа Юнысова әйтмешли, табигате матур булгач, кешеләре дә шундый. «Сабан туйларын ел да сагынып көтеп алабыз, бер елны да калдырмыйбыз. Үз аягымда йөргәндә ничек бәйрәмнән калмак кирәк ди?»

Бердәмлек сакчысы

Кунактан-кунакка йөри торгач, бәйрәмнең рәсми ачылышы билгеләнгән сәгать тә килеп җитте. Ульян һәм Татарстанның иҗат коллективлары әзерләгән бер сәгатьлек ачылыш тантанасын күз дә йоммый карадык. Уенлы, җырлы-биюле генә түгел, туйлы да иде әле ул. Башта хезмәт туе булды, басу-кырлардагы язгы эшләр турында сөйләп, Сабан туеның тарихы белән таныштырдылар. Аннан соң ике чиктәш төбәкне «туганлаштырдылар».

Шуннан соң кунакларны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов котлады.

– Барыгызны да татар халкының иң яраткан бәйрәме белән тәбрик итәм! Ульян өлкәсенең җитәкчеләренә, оештыручыларга зур рәхмәтемне белдерәм. Бик яхшы әзерләнгәннәр. Быел Сабан туе Россиянең 58 өлкәсе һәм 35 чит илдә уза. Ул бөтен татар халкының гореф-гадәтләрен, телен, динен сакларга ярдәм итә, – диде Президент.

Ульян өлкәсе губернаторы Алексей Русских сүзен, рәхмәтегезгә рәхмәт, дип башлады.

– Федераль Сабан туен кабат Ульян җирендә уздыруыбыз белән горурланам. Әлеге бәйрәм инде күптән гомуммилли мәдәни-тарихи байлыгыбызга әйләнде. Сабантуй тынычлык, игелек, татулыкны гәүдәләндерә. Ә быел бу төшенчәләр аеруча актуаль, – диде ул.

Котлау сүзләре җиткерелгәннән соң, федераль Сабан туеның символы – «Тулпар ат»ны бәйрәмнең киләсе елдагысы узачак төбәккә – Кемеровога тапшырдылар. Аны өлкә губернаторы Сергей Цивилев кабул итеп алды.

tatarstan.ru

Киң җилкәле батырлар

Сабантуйның иң кайнар ноктасы – көрәшне читләтеп узу гөнаһка тиң булыр иде. Бил алышканнарын тамаша кылырга килүчеләрне артык кайгыртып тормасалар да, көрәш мәйданы һәрьяклап әйләндереп алынган иде. Алты рәткә тезеп куелган эскәмиягә генә сыешып бетми шул көрәш сөючеләр...

Без килгәндә, соңгы ярышлар иде инде. Шуңа күрә ниләр булганын Чувашиянең Шыгырдан авылыннан килгән абзыйдан сорашырга туры килде. Ел саен килә икән Ульян каласындагы Сабан туена. Быелгы көрәшне бик мактады, чиста бил алышалар, көчле егетләр җыелган, ди.

Легендар спортчы Хәбил Бикташев та шулай ди. «Егетләргә алдан ук, матур көрәш күрсәтегез, дип әйтеп куйдым. Алыш-бирешкә урын юк монда. Һәм шулай көрәшәләр дә. Чыннан да, монда көчле егетләр җыелган – бик матур күренеш», – диде ул безгә.

Шактый макталган егетләрнең үзләре белән сөйләштек. 65 кг үлчәү авырлыгында батыр калган Ульян егете Артур Хәкимов өчен көрәш спорт төре генә түгел. «Ульян өлкәсе өчен 10 еллап көрәшәм. Федераль Сабан туе була дигәч, тренировкаларга көненә икешәр мәртәбә йөрдем. Монда җиңү минем өчен мөһим иде. Безнең бит бабаларыбыз да Сабантуйларда бил алышып, батыр исемен йөрткән. Минем өчен көрәш – традицияләрне олылауның бер юлы», – ди егет.

Абсолют батыр исеменә Татарстаннан Булат Мусин һәм Ульяннан Сергей Павлик көрәште. Булат – 100 кило үлчәү авырлыгында бил алышса, Сергей Павликның авырлыгы 180 килодан артык. Келәмдә басып торучы бу ике баһадирны күз алдына китергәнсездер бит? Бил алышуларының да ничегрәк булганын чамалыйсыздыр. Ахыр чиктә Павлик җиңде. Ульян өчен көрәшүче баһадирга тәкә һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның махсус бүләге – машина тапшырылды.

– Машинам ватылган иде, бик яхшы булды әле. Чынында исә мин бу җиңүемә бик сөенәм. Федераль Сабан туенда батыр калганым юк иде әле. Ульян өчен көрәшеп, шушы җирлектә батыр калу – икеләтә шатлык, – диде баһадир. – Күреп торасыз инде, көндәшем миннән бераз гына кечкенә. Ләкин тәртибе шундый бит.

Булат исә артык борчылмады кебек. Рөстәм Миңнеханов та борчылмаска киңәш иткән бит.

– Яныма килеп: «Борчылма, киләсе елга җиңәрсең әле», – диде ул. Миңа калса, Павлик – иң көчле көрәшчеләрнең берсе. Авырлыкларны чагыштырсак та, миннән ике тапкыр диярлек авыррак ул. Соңгы арада үз авырлыгыбыздагы егетләр белән көрәшеп күнеккән. Бүген мин канәгать. Үз үлчәвемдә, көндәшемне чистага атып, батыр калдым, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ,
РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 286

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+